РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«23» октября 2024г.

№ 129

О внесении изменений в постановление Исполнительного комитета Тюлячинского муниципального района от 26.09.2024 № 117 «Об утверждении нормативов финансирования деятельности образовательных организаций, реализующих программы дошкольного образования в Тюлячинском муниципальном районе на 2025 год»

В соответствии с Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Исполнительный комитет Тюлячинского муниципального района

ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Внести в постановление Исполнительного комитета Тюлячинского муниципального района от 26.09.2024 № 117 «Об утверждении нормативов финансирования деятельности образовательных организаций, реализующих программы дошкольного образования в Тюлячинском муниципальном районе на 2025 год» следующие изменения:

а) в преамбуле слова «постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 30.12.2013 года № 1096 «О нормативном финансировании деятельности дошкольных образовательных организаций Республики Татарстан» заменить словами «постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 02.07.2019 № 546 «О нормативном финансировании деятельности муниципальных дошкольных образовательных организаций»;

а) Перечень лиц, на которых распространяются льготы при внесении родительской платы за присмотр и уход за детьми в дошкольных образовательных организациях в Тюлячинском муниципальном районе Республики Татарстан на 2025 год, утвержденный пунктом 1.5 указанного постановления изложить в следующей редакции:

- «Перечень лиц, на которых распространяются льготы при внесении родительской платы за присмотр и уход за детьми в дошкольных образовательных организациях в Тюлячинском муниципальном районе Республики Татарстан на 2025 год

Родительская плата за присмотр и уход за детьми в дошкольных образовательных организациях Тюлячинского муниципального района не взимается:

- за присмотр и уход за детьми-инвалидами, за детьми-сиротами и детьми, оставшимися без попечения родителей, а также за детьми в дошкольных образовательных организациях с туберкулезной интоксикацией;

- с родителей, имеющих трех и более несовершеннолетних детей, родительскую плату за присмотр и уход за ребенком в дошкольных образовательных организациях снизить на 50 процентов;

- с семей, в которых один из родителей инвалид 1 группы, воспитывающих двоих детей, которые посещают дошкольную образовательную организацию;

- с семей, в которых один из родителей инвалид 1 группы, воспитывающих одного ребенка, посещающего дошкольное образовательное учреждение и имеющих среднедушевой доход ниже прожиточного минимума;

- с родителей (законных представителей) за присмотр и уход за ребенком в муниципальных образовательных организациях, реализующих программы дошкольного образования, для детей из семей (членам семей) граждан, участвующих в специальной военной операции, из числа граждан, призванных на военную службу по мобилизации в Вооруженные Силы Российской Федерации, военнослужащих и лиц, проходящих службу в национальной гвардии Российской Федерации, граждан, проходящих военную службу в батальонах «Алга» и «Тимер», сформированных в Республике Татарстан, граждан, добровольно выполняющих военные задачи в ходе специальной военной операции, сотрудников Министерства внутренних дел по Республике Татарстан, Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан, командированных в зону проведения специальной военной операции, а также семьям (членам семей) вышеуказанных категорий граждан, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции.

Льгота на оплату за присмотр и уход за детьми в муниципальных образовательных организациях предоставляется на основании заявления родителей (законных представителей) и документов, подтверждающих наличие у семьи права на льготу.

При наличии у семьи права на несколько льгот применению подлежит одна льгота по выбору родителей (законных представителей).»;

2. Настоящее постановление вступает в силу с 1 января 2025 года.

3. Опубликовать настоящее постановление в соответствии с действующим законодательством.

4. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на заместителя Руководителя Исполнительного комитета Тюлячинского муниципального района по социальным вопросам Д.С. Гиниятуллина.

Руководитель И.Х. Хамидуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с. Тюлячи КАРАР

«23» октябрь 2024ел № 129

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 сентябрендәге 117 номерлы 2025 елга Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 сентябрендәге 117 номерлы 2025 елга Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

а) күрсәтлгән карарның 1.5 пункты белән расланган, 2025 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенә ташламалар кертелгән затлар исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «2025 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында
балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвенә ташламалар кертелгән затлар исемлеге

Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве алынмый:

- инвалид балаларны, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук туберкулез интоксикациясе булган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен;

- өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган ата-аналардан мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә баланы тәрбияләгән һәм караган өчен ата-аналар түләвен 50 процентка киметергә;

- ата-аналарның берсе 1 инвалид, ике бала тәрбияләүче, мәктәпкәчә белем бирү оешмасында йөрүче гаиләләрдән;

- ата-аналарның берсе 1 төркем инвалид, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче бер бала тәрбияләүче һәм җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләрдән;

- мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең гаиләләрен (гаилә әгъзаларын), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләре гаиләләрен (гаилә әгъзаларына).

Муниципаль белем бирү учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүгә ташлама ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы һәм гаиләнең ташламага хокукы булуын раслаучы документлар нигезендә бирелә.

Гаиләнең берничә ташламага хокукы булганда, ата-ана (законлы вәкилләр) сайлау буенча бер ташлама кулланылырга тиеш.»;

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин